| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 май № 365

г. Казань

Барлык бүлмәләре Татарстан Республикасы милкендә булган наемга бирелгән йортлар һәм наемга бирелгән йортлар булып торган вә Татарстан Республикасы милкендә булган торак йортлар белән идарә итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.20 статьясы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Барлык бүлмәләре Татарстан Республикасы милкендә булган наемга бирелгән йортлар һәм наемга бирелгән йортлар булып торган вә Татарстан Республикасы милкендә булган торак йортлар белән идарә итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 май, 365 нче
карары белән расланды

Барлык бүлмәләре Татарстан Республикасы милкендә булган наемга бирелгән йортлар һәм наемга бирелгән йортлар булып торган вә Татарстан Республикасы милкендә булган торак йортлар белән идарә итү
тәртибе

1. Әлеге Барлык бүлмәләре Татарстан Республикасы милкендә булган наемга бирелгән йортлар һәм наемга бирелгән йортлар булып торган вә Татарстан Республикасы милкендә булган торак йортлар белән идарә итү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Торак кодексының 91.20 статьясы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә эшләнде һәм барлык бүлмәләре Татарстан Республикасы милкендә булган наемга бирелгән социаль һәм коммерциячел кулланыштагы йортлар (алга таба – күпфатирлы наемга бирелгән йортлар) һәм наемга бирелгән йортлар булып торган вә Татарстан Республикасы милкендә булган торак йортлар белән идарә итү кагыйдәләрне билгели.

2. Күпфатирлы наемга бирелгән йорт белән идарә итү Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 1 – 1.2, 15 һәм 16 өлешләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт торак фондының торак урыннары милекчесе сыйфатында Татарстан Республикасы исеменнән наемга бирелгән йортта торак урыннарны наемга бирүче вазыйфаларын үтәү хокукы бирелгән оешма (алга таба – идарә итәргә хокуклы наемга бирүче);

б) Россия Федерациясе Торак кодексының X бүлегендә билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензия бирелгән идарә оешмасы, әгәр күпфатирлы йортта торак урыннарны наемга бирүче булып идарә итәргә хокуклы наемга бирүче (алга таба – идарәче оешма) торган очракта.

3. Идарә итәргә хокуклы наемга бирүче Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды милекчесе сыйфатында Татарстан Республикасы исеменнән чыгарга вәкаләтле, Татарстан Республикасы милкендәге наемга бирелгән йорт булган күпфатирлы наемга бирелгән йорт һәм торак йорт белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча барлык хезмәтләрне күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару өчен техник регламентларда билгеләнгән таләпләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, аны карап тоту һәм

ремонтлау буенча тиешле сыйфатлы булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып киткән хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләме үзгәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 13 август, 491 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тоту өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләрнең минималь исемлеге һәм аларны күрсәтү вә башкару тәртибе турында» 2013 ел, 3 апрель, 290 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тоту өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләрнең минималь исемлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 ел, 15 май, 416 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда бүлмәләр һәм торак йортлар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 ел, 6 май, 354 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортларда бүлмәләр һәм торак йортлар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында җавап тота.

4. Идарә итүче оешма:

а) Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясы нигезендә идарә итәргә хокуклы наемга бирүче белән төзелгән идарә итү шартнамәсе буенча күпфатирлы наемга бирелгән йорт белән идарәне гамәлгә ашыра;

б) Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 2.3 өлештә билгеләнгән таләпләр нигезендә наемга бирелгән күпфатирлы йорт белән идарә иткән, аны карап тоткан һәм ремонтлаган вә бу йорттагы бүлмәләрдән файдаланучы затларга коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен идарә итәргә хокуклы наемга бирүче каршында җавап тота.

5. Күпфатирлы наемга бирелгән йорт белән идарә итү әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән идарәче оешма тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта мондый идарәче оешманы сайлап алуны федераль законнар таләпләре нигезендә идарә итәргә хокуклы наемга бирүче тарафыннан башкарыла.

6. Наемга бирелгән йортлар һәм Татарстан Республикасы милкендәге торак йортлар белән идарә итү техник регламентларда билгеләнгән таләпләр һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган күпфатирлы йортларда бүлмәләр һәм торак йортлар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.